**СОВЕТ ДЕРЖАВИНОСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422620,Татарстан, с. Державиноо,
ул. Заббарова, д.39
тел: 3-45-20

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДЕРЖАВИНОО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422620 Державиноо авылы,
Заббаров урамы, 39 нчы йорт,
тел: 3-45-20

---

**2020елның 10 ноябре** **19номер**

# К А Р А Р

**Державиноо авыл җирлеге Советының 2020 елның 29 сентябрендәге 7 номерлы «Державино авыл җирлегенең муниципаль вазыйфасын биләгән затка тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы нигезләмә турында " карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Державино авыл җирлеге Уставы нигезендә Державино авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Державино авыл җирлегенең муниципаль вазыйфасын биләүче затка тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алуга бәйле рәвештә бер тапкыр акчалата бүләкләү тәртибе турындагы нигезләмә хакында» 2020елның 29 сентябрендәге 7 номерлы Державино авыл җирлеге Советы карарына үзгәреш кертергә, кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек Советының план-бюджет комиссиясенә һәм икътисадый үсешенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Державино авыл җирлеге Советы рәисе** **И.И.Камалиева**

**2020 елның 28 октябрендәге**
**19 номерлы Державино авыл җирлеге**
**Советы карарына кушымта**

Державино авыл җирлеге муниципаль вазыйфасын биләгән затка тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

1. 2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон) нигезендә картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясе билгеләнеше.»

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирүче яшькә җиткәч яисә «иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә инвалидлык буенча пенсия билгеләгәндә, муниципаль хезмәткәрнең гаепле гамәлләренә бәйле эштән азат ителүдән тыш, һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда, муниципаль хезмәттән азат ителү аңлашыла.»;

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Державино авыл җирлеге Советы рәисе** **И.И.Камалиева**